**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 4 февраль № 66

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен (гражданнар оборонасы хезмәтләрен) оештыру турында» 2010 ел, 15 гыйнвар, 6 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 18 октябрь, 862 нче; 2012 ел, 27 апрель, 331 нче; 2013 ел, 27 апрель, 287 нче; 2014 ел, 6 октябрь, 716 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында коткару хезмәтләрен (гражданнар оборонасы хезмәтләрен) формалаштыру һәм алар тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашыру тәртибендә:

I бүлекнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Коткару хезмәте (гражданнар оборонасы хезмәте) (алга таба – гражданнар оборонасы хезмәте) – ул хәрби каршылыкларда яки әлеге каршылыклар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә һәм террорчылык актларында гражданнар оборонасы буенча чаралар үткәрү, авария-коткару формированиеләренең гамәлләрен төрле яклап тәэмин итү һәм башка кичектергесез эшләр башкару өчен билгеләнгән идарә органнары, гражданнар оборонасы көчләре һәм чаралары берлеге.»;

III бүлектә:

2.4 пунктның өченче абзацында «хәрби хәрәкәтләр алып барганда яки әлеге хәрәкәтләр нәтиҗәсендә» сүзләрен «хәрби каршылыкларда яки әлеге каршылыклар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү турындагы нигезләмәдә:

4 пунктта:

беренче абзацта «укыту» сүзен «әзерләү» сүзенә алмаштырырга;

икенче абзацта «укыту» сүзен «әзерләү» сүзенә алмаштырырга;

өченче абзацта «өстәмә һөнәри белемнең (квалификация күтәрү) белем бирү учреждениеләре» сүзләрен «өстәмә һөнәри белемнең белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта:

беренче абзацта «хәрби хәрәкәтләр алып барганда яки әлеге хәрәкәтләр нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда» сүзләрен «хәрби каршылыкларда яки әлеге каршылыклар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «Татарстан Республикасы ГТХМ» сүзләреннән соң «, җирле үзидарә органнары һәм I һәм II класслы куркынычлы куркыныч җитештерү объектларын файдаланучы оешмалар, аеруча нурланышлы куркыныч һәм атом-төш куркыныч булган җитештерүләр һәм объектлар, куркынычлылыгы гадәттән тыш югары гидротехник корылмалар һәм куркынычлылыгы югары гидротехник корылмалар, шулай ук билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы категориясенә кертелгән оешмалар» сүзләрен өстәргә;

6 пунктның дүртенче абзацында «районнар» сүзләрен «өчен куркынычсыз районнар» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта:

беренче абзацта «саклану урыннары һәм шәхси саклану чаралары» сүзләрен «шәхси һәм коллектив саклану чаралары» сүзләренә алмаштырырга;

өченче һәм дүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«халыкны яшерер өчен тыныч вакытта һәм гражданнар оборонасын аны алып баруга әзерлеккә китергәндә һәм сугыш вакытында аны алып барганда тирәнәйтелгән биналарны һәм җир асты киңлегендәге башка корылмаларны;

гражданнар оборонасының гадиләштерелгән эчке җиһазлары белән тиз корыла торган саклану корылмаларын һәм гади төрдәге яшеренү урыннарын тыныч вакытта әзерләү һәм гражданнар оборонасын аны алып баруга әзерлеккә китергәндә һәм сугыш вакытында аны алып барганда төзү. Күрсәтелгән чараларны үтәүне оештыру Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләнә;»;

8 пунктта:

беренче абзацта «яктылык һәм башка төр маскировка белән тәэмин итү» сүзләрен «яктылык маскировкасы һәм маскировканың башка төрләре буенча чаралар үткәрү» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы категорияләренә кертелгән оешмалар һәм гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәүне тәэмин итүче оешмалар тарафыннан яктылык маскировкасы һәм маскировканың башка төрләре буенча чаралар үткәрү өчен кирәкле матди-техник чаралар запасларын булдыру һәм аларны билгеләнеше буенча файдалану өчен даими әзерлек хәлендә тоту;»;

9 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Хәрби каршылыкларда яки әлеге каршылыклар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә һәм террорчылык актларында халык өчен куркынычлар килеп чыккан очракта авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр үткәрү белән бәйле мәсьәләләрне хәл итү максатында гамәлгә ашырыла торган гражданнар оборонасы буенча төп чаралар түбәндәгеләр:»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гражданнар оборонасы өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җәлеп ителә торган штаттан тыш авария-коткару формированиеләре һәм гражданнар оборонасы буенча төбәк дәрәҗәсендәге чараларны үтәүне тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләр реестрларын исәпкә алу һәм алып бару.»;

10 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Хәрби каршылыкларда яки әлеге каршылыклар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән халыкны беренче чиратта тормыш иминлеген тәэмин итү белән бәйле мәсьәләне хәл итү максатларында гамәлгә ашырыла торган гражданнар оборонасы буенча төп чаралар түбәндәгеләр:»;

сигезенче абзацта «хәрби хәрәкәтләр алып барганда яки әлеге хәрәкәтләр нәтиҗәсендә» сүзләрен «хәрби каршылыкларда яки әлеге каршылыклар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның икенче абзацында «хәрби хәрәкәтләр алып барганда яки әлеге хәрәкәтләр нәтиҗәсендә» сүзләрен «хәрби каршылыкларда яки әлеге каршылыклар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктта:

беренче абзацта «һәм бүтән» сүзләрен «яки бүтән» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «пычрану» сүзен «агулану (пычрану)» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктның беренче абзацында «хәрби хәрәкәтләр алып барганда яки әлеге хәрәкәтләр нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда» сүзләрен «хәрби каршылыкларда яки әлеге каршылыклар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә һәм террорчылык актларында» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Хәрби каршылыкларда яки әлеге каршылыклар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә халыкның исән калуы өчен

кирәкле оешмаларның тотрыклы эшләвен тәэмин итү белән бәйле мәсьәләне хәл итү максатларында гамәлгә ашырыла торган гражданнар оборонасы буенча төп чаралар түбәндәгеләр:».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 2 ноябрь, 837 нче карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 28 май, 380 нче, 2015 ел, 12 ноябрь, 849 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү» дәүләт программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«I. Программаны тормышка ашыру тармагына гомуми тасвирнамә, төп проблемалар һәм аларны хәл итү юллары» бүлегендә:

утыз алтынчы абзацта:

«мәгариф учреждениеләре» сүзләрен «мәгариф оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

«сәламәтлек саклау» сүзләрен «медицина оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

кырык бишенче абзацта «сәламәтлек саклау» сүзләрен «медицина оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

илле өченче абзацта:

«мәгариф учреждениеләре» сүзләрен «мәгариф оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

«сәламәтлек саклау» сүзләрен «медицина оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

алтмыш икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә әзерлек.»;

җитмеш җиденче абзацта «мәгариф учреждениеләрендә» сүзләрен «мәгариф оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

дәүләт программасына 1 нче кушымтада:

2 пунктта «Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге» 3 графада «вазыйфаи затларны һәм белгечләрне укыту» сүзләрен «вазыйфаи затларны һәм белгечләрне әзерләү» сүзләренә алмаштырырга;

«2014 – 2002 елларга Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгы» ярдәмче программасында:

«I. Ярдәмче программаны тормышка ашыру тармагына гомуми тасвирнамә, төп проблемалар һәм аларны хәл итү юллары» бүлегендә:

унберенче абзацта:

«мәгариф учреждениеләре» сүзләрен «мәгариф оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

«сәламәтлек саклау» сүзләрен «медицина оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

кырык дүртенче абзацта «мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре, гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучылар» сүзләрен «мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, гомуми белем бирү оешмаларында укучылар» сүзләренә алмаштырырга;

«II. Ярдәмче программаның, аны тормышка ашыруның сроклары һәм этапларының төп максатлары, бурычлары, чаралары, көтелә торган төп соңгы нәтиҗәләрне тасвирлау» бүлегендә:

йөз егерме өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Янгын, авария, ЮТФ урынында авария-коткару эшләрен үткәргәндә шәхси составны саклауны тәэмин итү өчен Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Россия Федерациясе субъектлары буенча Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының баш идарәләрен матди-техник чаралар белән тәэмин итү нормаларын раслау турында» 2015 ел, 13 гыйнвар, 5 нче боерыгы нигезендә бүлекчәләрнең нурланышка каршы һәм химиядән саклау өчен кирәкле мөлкәт комплектлары булырга тиеш. Татарстан Республикасының янгынга каршы хезмәте бүлекчәләрен нурланышка каршы һәм химиядән саклау өчен кирәкле мөлкәт комплектлау исәбе 9 таблицада китерелгән.»;

«2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычларын киметү һәм нәтиҗәләрен җиңеләйтү» ярдәмче программасында (алга таба – Ярдәмче программа):

Ярдәмче программа паспортының «Ярдәмче программаның бурычлары» юлында 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләү»;

«I. Ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсенә гомуми тасвирнамә, төп мәсьәләләр һәм аларны хәл итү юллары» бүлегендә:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ярдәмче программа Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 ел, 11 март, 390-б номерлы боерыгы белән расланган Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте арасында үз вәкаләтләренең бер өлешен бер-берсенә тапшыру турында килешү нигезендә Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы һәм Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе карамагында булган Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы, муниципальара һәм төбәк характерындагы гадәттән тыш хәлләрне, табигый бәла-казаларны кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү өлкәсендәге вәкаләтләрен тормышка ашыруга юнәлдерелгән. Килешүне үтәүне анализлау күрсәтүенчә, ул республикага да, федераль үзәккә дә үзләренә беркетелгән вәкаләтләр кысаларында чараларны тулы күләмдә, берсе икенчесен тулыландырып, әмма кабатлауларны булдырмыйча гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә. Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы һәм аның ведомствосындагы учреждениеләр килешү нигезендә Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең оператив идарәсендә була һәм Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрдән саклау, гражданнар оборонасы,

янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында иминлекне тәэмин итү вәкаләтләрен бергәләп үтиләр.»;

алтмыш бишенче абзацта «мәгариф учреждениеләре» сүзләрен «мәгариф оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

«II. Ярдәмче программаның, аны тормышка ашыруның сроклары һәм этапларының төп максатлары, бурычлары, чаралары, көтелә торган төп соңгы нәтиҗәләрне тасвирлау» бүлегендә:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләү.»;

җитмеш өченче абзацта «халыкны укыту» сүзләрен «халыкны әзерләү» сүзләренә алмаштырырга;

унтугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бяән итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 ел, 11 март, 390-б номерлы боерыгы белән расланган Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте арасында үз вәкаләтләренең бер өлешен бер-берсенә тапшыру турында килешүгә имза куелганны билгеләп үтәргә кирәк. Килешүне үтәүне анализлау күрсәтүенчә, ул республикага да, федераль үзәккә дә үзләренә беркетелгән вәкаләтләр кысаларында чараларны тулы күләмдә, берсе икенчесен тулыландырып, әмма кабатлауларны булдырмыйча гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә. Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы һәм аның ведомствосындагы учреждениеләр килешү нигезендә Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең оператив идарәсендә була һәм Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрдән саклау, гражданнар оборонасы, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында иминлекне тәэмин итү вәкаләтләрен бергәләп үтиләр.»;

җитмеш җиденче абзацта «учреждение» сүзен «оешма» сүзенә алмаштырырга;

Ярдәмче программага кушымтада:

«5 бурыч «Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны укыту» юлы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 бурыч «Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләү»;

«2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасында «Имин шәһәр» аппарат-программа комплексын төзү һәм үстерү» ярдәмче программасында:

«I. Ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсенә гомуми тасвирнамә, төп мәсьәләләр һәм аларны хәл итү юллары» бүлегенең утыз икенче абзацында «укыту учреждениеләре» сүзләрен «мәгариф оешмалары» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы һәм муниципаль берәмлекләр территорияләренең иминлек паспортларын эшләү турында» 2005 ел, 12 декабрь, 591 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы һәм муниципаль берәмлекләр территорияләренең иминлек паспорты турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«I. Территориянең гомуми тасвирнамәсе» бүлегендә:

18 юлда:

«мәгариф, медицина учреждениеләре » сүзләрен «мәгариф оешмалары, медицина оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

«VI. Территориядә халыкны саклау, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү буенча оештыру-техник чаралар тасвирнамәсе» бүлегендә:

1 юлда «мәгариф учреждениеләре, медицина учреждениеләре» сүзләрен «мәгариф оешмалары, медицина оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

49 юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«49. Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау мәсьәләләре буенча әзерлек узган предприятиеләрнең җитәкче хезмәткәрләре, шул исәптән гадәттән тыш хәлләр булырга мөмкин зоналарда урнашкан объектлар җитәкчеләре саны, кеше һәм аларның гомуми санынннан %»;

50 юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«50. Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау мәсьәләләре буенча әзерлек узган предприятиеләр һәм оешмалар, шул исәптән гадәттән тыш хәлләр булырга мөмкин зоналарда урнашкан гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерлек мәсьәләләре буенча әзерлек узган предприятиеләр һәм оешмалар саны, кеше һәм гадәттән тыш хәлләр булырга мөмкин зоналарда урнашкан предприятиеләр һәм оешмалар персоналының гомуми санынннан %»;

51 юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«51. Яшәү урыны буенча гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау мәсьәләләре буенча әзерлек узган, шул исәптән гадәттән тыш хәлләр булырга мөмкин зоналарда яшәүче халык саны, кеше һәм гадәттән тыш хәлләр булырга мөмкин зоналарда яшәүче халыкның гомуми санынннан %»;

52 юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«52. Белем бирү оешмаларында укучы гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау мәсьәләләре буенча, шул исәптән гадәттән тыш хәлләр булырга мөмкин зоналарда урнашкан оешмаларда әзерлек узган укучылар саны, кеше һәм укучыларның гомуми санынннан %».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2006 ел, 14 август, 409 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 22 март, 233 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы турында» 1997 ел, 23 июль, 588 нче;

«Хосусыйлаштырылган предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан гражданнар оборонасы объектларын һәм мөлкәтен файдалану тәртибе турында» 1998 ел, 1 апрель, 168 нче;

«Татарстан Республикасының автотранспорт предприятиеләре тарафыннан гражданнар оборонасының автосанитар отрядларын формалаштыру буенча вазыйфаларын яңадан бүлүне исәпләүне раслау турында» 1998 ел, 26 май, 298 нче;

«2001 – 2005 елларга Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм әзерләү буенча гамәли чаралар планын раслау турында» 2000 ел, 13 июнь, 400 нче;

«Аерым чорда гражданнар оборонасы мәнфәгатьләрендә ведомство элемтә челтәрләрен куллану буенча чаралар планын раслау турында» 2001 ел, 22 гыйнвар, 22 нче;

«Татарстан Республикасының мәдәни кыйммәтләрен яклау буенча гражданнар оборонасы хезмәтен төзү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы хезмәтләре составын раслау турында» 2001 ел, 17 август, 553 нче карарына өстәмә кертү хакында» 2000 ел, 30 май, 06-135 нче;

«2006 елга гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасының төп чаралары планын һәм Татарстан Республикасының идарә органнарын, гражданнар оборонасы көчләрен һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системаны әзерләү буенча оештыру-методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2006 ел, 10 апрель, 161 нче;

«Татарстан Республикасы гражданнар оборонасының автосанитар отрядларын формалаштыру турында» 2006 ел, 14 август, 412 нче;

«Татарстан Республикасы территориясендә Иминлек паспортын эшләү буенча чаралар турында» 2006 ел, 28 декабрь, 647 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы гражданнар оборонасының автосанитар отрядларын формалаштыру турында» 2006 ел, 14 август, 412 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 ел, 16 май, 182 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы гражданнар оборонасының автосанитар отрядларын формалаштыру турында» 2006 ел, 14 август, 412 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 ел, 11 февраль, 73 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\66.docx